Безнең балалар бакчасында заманча методик алымнар һәм чаралар куллану, татарча мультфильмнарны, электрон ярдәмлекләрне, аудио һәм видеоматерилларны файдалану мөһим урынны алып тора.





Укыту-методик комплектының юнәлешләре күптөрле. Алар балалар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч итеп эшләнелгән. Һәрбер юнәлеш билгеле бер үзенең максатын чишә. Эш дәфтәрләре – заманча төзелгән укыту-методик комплектының төп юнәлешләренең берсе булып тора.



Укыту дәверендә бик еш кына эш дәфтәрләрен кулланам.Дәфтәрләр белән эшләгәндә балалар кабатлыйлар, бер-берсенә сораулар бирәләр, тәрбияче белән аралашалар. Бик уңай ягы, балалар үзләренең шөгыльдә эшләгән дәфтәрләрен өйгә алып кайтып кабатлый алалар. Балалар эш дәфтәрләре белән шөгыльләнергә бик яраталар.




